ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2020 Казан ш. № 436-77/тэ-2020

Кулланучыларга «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 5-46/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021-2022 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021-2022 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 № 5-46/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2019 № 5-46/тэ
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2020 № 436-77/тэ-2020
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

# 2020-2022 елларга «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Лениногорск муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Ленингорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1679,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1714,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1714,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1743,67 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1743,67 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1857,08 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 2014,80 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 2057,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 2057,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 2092,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 2092,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2228,50 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге